**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

03.03.2022 № 111

**2022 елда Казан шәһәрендә ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитетының 45 нче сессиясен әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә:

Татарстан Республикасы Президентының «2022 елда Казан шәһәрендә ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитетының 45 нче сессиясен оештыру һәм уздыру турында» 2021 елның 30 июлендәге 216 номерлы боерыгы белән расланган 2022 елда Казан шәһәрендә ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитетының 45 нче сессиясен әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) оештыру комитеты составыннан А.И. Афанасьевны, И.Р. Гафуровны, А.М. Сибагатуллинны, Д.И. Фәттаховны, Р.С. Хәкимовны чыгарырга;

б) оештыру комитеты составына кертергә:

Воронцов Андрей Юрьевичны – Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Саратов һәм Самара өлкәләре буенча чик буе идарәсе «Идел буе» чик буе контроль отрядының «Казан-аэропорт» контроль-үткәрү пункты башлыгын (килешү буенча);

Рәхимов Илнур Сөләйман улын – «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе директорын (килешү буенча);

Сөләйманов Тимур Җәүдәт улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын;

Сөнгатуллина Зөлфия Хафиз кызын – «Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу республика фонды» коммерциячел булмаган оешмасы башкарма директорын (килешү буенча);

Таюрский Дмитрий Альбертовичны – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын башкаручыны (килешү буенча);

в) оештыру комитеты әгъзасы Т.П. Ларионованың вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты, оештыру комитеты рәистәшенең урынбасары (килешү буенча)».

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**